**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» февраль 2020 с. Тюлячи № 66

Теләче муниципаль районында 2020-2022 елларга хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча территориаль программа

Теләче муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 35.1, 210 статьяларына таянып, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районында 2020-2022 елларга хезмәтне саклау шартларын яхшырту буенча территориаль программаны кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«19» 02 2020 ел
66 номерлы карары белән
расланган

# I. Паспорт
# Теләче муниципаль районында 2020-2022 елларга хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча территориаль программа

| Программаның исеме | Теләче муниципаль районында 2020-2022 елларга хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча территориаль программа |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигезләр | - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;<br>- «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы законы |
| Программаны төп эшләүчеләр | - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координацион совет;<br>- Теләче муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары |
| Программаның максаты: | «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган хезмәтне саклауга һәм шартларга Конституциячел гарантияләрне тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1. Производствода җәрәхәтләнү һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү.<br>2. Оешмаларда хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын яхшырту |
| Программаны тормышка ашыруның иң мөһим максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) | - Производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күрүчеләр саны;<br>- Җитештерү имгәнүләре һәм җәрәхәтләнүләре белән бәйле бер зыян күргән кешегә исәпләгәндә эшкә яраксызлык көннәре саны;<br>- Санитар-гигиена нормаларына туры килми торган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы;<br>- Авыр физик хезмәт белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2020-2022 еллар |
| Программаны финанслау чыганаклары | Тиешле финанс елына Теләче муниципаль районы бюджеты, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар акчалары:<br>2020 ел - 2000 мең сум;<br>2021 ел - 2000 мең сум;<br>2022 ел - 2000 мең сум |

| | |
|---|---|
| Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре | Программа максатларына һәм бурычларына ирешү индикаторлары (күрсәткечләре) :<br>- 1 һәм күбрәк эш көненә эшкә яраклылык югалып, производствода бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләр саны (кеше);<br>- 1 мең эшчегә исәпләгәндә производствода үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә һәлак булучыларның чагыштырма саны, 1 мең кешегә исәпләнгәндә;<br>- санитар-гигиена нормаларына җавап бирми торган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы (шәһәр икътисадында эшләүчеләрнең гомуми саныннан%);<br>- хезмәт шартлары буенча аттестацияләнгән эш урыннарында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы, шәһәр икътисадында эшләүчеләрнең гомуми саныннан;<br>- вакытлы медицина күзәтүе белән тәэмин ителгән хезмәткәрләр саны |
| Көтелгән соңгы нәтиҗәләр | 1. Социаль эффект:<br>- начар хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын киметү;<br>- җитештерү имгәнүләрен һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү;<br>- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- хезмәткәрләргә куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итүгә Конституциячел хокукны гамәлгә ашыру.<br>2. Икътисади нәтиҗә:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү;<br>- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү;<br>- зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында, авыр хезмәт шартлары булган эш өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;<br>- производствода имгәнү яки һөнәри авыру аркасында инвалидлык дәрәҗәсен һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә чыгымнарны киметү;<br>- эш вакытын югалтулар хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;<br>- травмалар һәм производство билгеләнешендәге авырулар аркасында, җитәрлек тәҗрибәсе һәм квалификациясе булмаган төп хезмәткәрләрне авырган вакытта алыштыручы вакытлыча хезмәткәрләр тарафыннан ремонт һәм алмаштыруга киткән чыгымнарны киметү; |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координацион совет;<br>- дәүләт күзәтчелек һәм контроль органнары |

Кеше сәламәтлеге социаль кыйммәтләр системасында әйдәп баручы урынны алып тора һәм дәүләтнең мөһим ресурсы буларак карала. Һөнәри авырулар, имгәнүләр бөтен дәүләткә зыян китерә, һәм бу һөнәри куркыныч дәрәҗәсен киметүгә һәм хезмәт шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар үткәрүне таләп итә.

Хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышына йогынты ясый торган төп факторлар булып тора: икътисад торышы, фәнни-техник прогресс, тиешле закон һәм норматив хокукый актларда беркетелгән, хезмәтне саклау белән идарә итү өлкәсендә дәүләт сәясәте һәм аларны үтәү дәрәҗәсе. Хезмәт ияләренең хезмәтне саклау турында Россия Федерациясе законнары, хезмәтне саклау буенча башка норматив хокукый актлар, шул исәптән гигиена һәм хезмәт медицинасы буенча да, билгеләнгән сәламәт һәм имин хезмәт шартларына хокуклары практикада һәрвакыт тәэмин ителми, чөнки күп очракта аларны тормышка ашыру механизмнары юк.

Теләче районы 1935 елда оеша. 1959 елда ТАССР Югары Советы Президиумы карары белән Теләче районы бетерелә, ә территория Саба районына тапшырыла. 1991 елның 28 ноябрендә Татарстан Республикасы Югары Советы кабат Теләче районын торгыза.

Район республика башкаласыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә урнашкан. Казаннан Теләче авылы район үзәгенә кадәр ераклык 78 км тәшкил итә.

Район төньякка таба Саба, көнчыгышта Мамадыш, көньяк-көнчыгышта Балык Бистәсе, көньяк-көнбатышта Питрәч һәм төньяк-көнбатышта Арча районнары белән чиктәш. Якындагы тимер юл станциясенә- Арчага кадәр 39 км. Теләче муниципаль районы территориясендә 13,9 мең кеше яши, шуларның 80% - татарлар, 11% - руслар, 9% – башка милләт вәкилләре.

Теләче районы авыл хуҗалыгы районы булып тора. Районның авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданы 58762 гектар тәшкил итә, шул исәптән 49428 гектар сөрүлек җирләре дә бар. Районда авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән төрле милек рәвешләрендәге 30 артык хуҗалык итүче субъект шөгыльләнә.

Үсемлекчелек һәм терлекчелек-район агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып торалар.

Теләче муниципаль районы территориясендә2020 елның 1 гыйнварына 248 предприятие һәм оешма эшли, аларда 4446 кеше хезмәт итә.

Районның эшләүче халкына хезмәтне саклау буенча уңай шартлар тудыру белән идарә итү өчен Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 16 мартындагы 235 номерлы карары белән Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты каршында хезмәтне саклау буенча Координация советы төзелде. Совет 8 кешедән тора: совет рәисе, совет рәисе урынбасары, җаваплы сәркатип һәм советның биш әгъзасы. 2019 елда Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы тарафыннан 12 утырыш үткәрелде.

2015 елда производствода бер бәхетсезлек очрагы булган, хезмәткәр таеп егылып, аягының уң табанының бер сөяген сындырган.

2016 елда Теләче муниципаль районы территориясендә 3 җиңел дәрәҗәдәге җәрәхәт очраклары булуы күзәтелгән.

2018 елда өч бәхетсезлек очрагы булды, шуларның берсе үлем белән тәмамланды.

2019 елда «Таң»ҖЧҖ Авыл хуҗалыгы предприятиесендә бер авыр бәхетсезлек очрагы булды.

Хезмәтне саклау өлкәсендәге хәлне яхшырту өлешендә район оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтне саклау мәсьәләләренә максатчан өйрәтүе мөһим. 2014 елда мәгариф өлкәсендә җитәкчеләр һәм белгечләр - 8 кеше, 13 кеше -авыл җирлеге башлыгы, 27 кеше - авыл хуҗалыгы предприятиесе белгече хезмәтне саклау буенча укулар узды.

2015 елда хезмәтне саклау өлкәсендәге хәлләрне яхшырту кысаларында Теләче районы мәгариф өлкәсе хезмәткәрләре категориясеннән 189 кеше укыды.

2016 елда районның авыл хуҗалыгы предприятиеләренең 60 белгече хезмәтне саклау буенча укулар узды, ә 2017 елда 57 белгеч белем алды. 2017 елда мәгариф өлкәсендә 19 хезмәткәр белем алды.

2018 елда районда хезмәтне саклау буенча авыл хуҗалыгы тармагы белгечләреннән 57 кеше, мәгариф бүлеге - 200, ә 2019 елда әлеге юнәлешләрдән 65 һәм 4 кеше укыды.

Әлеге Программаны кабул итү һәм гамәлгә ашыру хезмәтне саклау белән идарә итү системасының, кадрларны һөнәри әзерләү дәрәҗәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, оешмаларда хезмәтне саклау гамәлләренең эше өчен уңайлырак шартлар тудыруга ярдәм итәчәк, бу хезмәтне саклау өлкәсендәге вәзгыятьне яхшыртырга һәм, димәк, район халкының тормыш дәрәҗәсен индикатив бәяләү күрсәткечләренә йогынты ясарга мөмкинлек бирәчәк.

Производствода имгәнүләр саны

| | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлеге | | | | 3 | 1 |
| - шулар арасыннан үлем белән тәмамланганнары | 0 | 0 | 0 | 1 | 0 |

## II. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты булып, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында, куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган хезмәтне саклауга һәм шартларга конституцион гарантияләрне тәэмин итү тора.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү зарур:

- хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау;
- хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүне активлаштыру, оешмаларда хезмәтне саклау буенча эшләрне сертификацияләү һәм аларны үткәрү сыйфатын күтәрү;
- производствода бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны профилактикалау һәм кисәтү;
- эш урыннарының җәлеп итүчәнлеген арттыру.

## III. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм максатчан индикаторлары (күрсәткечләр)

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә көтелә:

1. Социаль эффект:

- начар хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын киметү;
- җитештерү имгәнүләрен һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү;
- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;
- хезмәткәрләргә куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итүгә Конституциячел хокукны гамәлгә ашыру.

2. Икътисади нәтиҗә:

- производствода бәхетсезлек очракларыннан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү;
- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү;
- зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында, авыр хезмәт шартлары булган эш өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;
- производствода имгәнү яки һөнәри авыру аркасында инвалидлык дәрәҗәсен һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә чыгымнарны киметү;
- эш вакытын югалтулар хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;
- имгәнүләр һәм производство билгеләнешендәге авырулар аркасында, җитәрлек тәҗрибәсе һәм квалификациясе булмаган вакытта төп хезмәткәрләрне алыштыручы вакытлыча хезмәткәрләр тарафыннан ремонт һәм алмаштыруга киткән чыгымнарны киметү.

Программаның максатына ирешү һәм бурычларын хәл итү программага Кушымтада китерелгән максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) белән бәяләнә.

Әлеге максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) ел саен хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк учреждениесе һәм федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан исәпләп чыгарыла һәм тапшырыла торган төп хезмәтне саклауның төп күрсәткечләреннән гыйбарәт.

Әлеге күрсәткечләрнең динамикасы башкарылган чараларның нәтиҗәлелеген күрсәтә.

Теләче муниципаль районында
2020-2022 елларга хезмәт шартларын
һәм хезмәтне саклауны яхшырту
буенча территориаль программага
кушымта

## Программаның 2020-2022 елларга максатлары, бурычлары, чаралары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Максат исеме | Бурыч исеме | Төп чараларның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | 2020-2022 елларга финанслау чоры | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган хезмәтне саклауга һәм аның шартларына Конституциячел гарантияләрне тәэмин итү | 1. Хезмәтне саклау белән идарә итү системасын үстерү | 1.1. Милекнең барлык оештыру-хокукый рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга бәяләү-конкурслар үткәрү;<br>1.2. Барлык дәрәҗәдәге бюджеттан финанслана торган предприятиеләр, кече эшмәкәрлек субъектлары һәм оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре өчен хезмәтне саклау буенча укулар;<br>1.3. Хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларында сәнәгать, энергетика куркынычсызлыгы һәм сәнәгать санитариясе чараларын яктырту;<br>1.4. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне гомумиләштерү һәм тарату;<br>1.5. "Производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү | Кыскартылма:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күрүчеләр саны;<br>- җитештерү имгәнүләре һәм җәрәхәтләнүләре белән бәйле бер зыян күргән кешегә исәпләгәндә эшкә яраксызлык көннәре санынnan чыгып;<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы;<br>- авыр физик хезмәт | 2000 мең сум | 2000 мең сум | 2000 мең сум |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | турында" 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чараларны үтәү | белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы | | | |
| | 2. Производствода имгәнүләр, һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү | 2.1. Хезмәтне саклау, сәнәгать, энергетика һәм экологик куркынычсызлык һәм санитар законнарны үтәү буенча хокукый норматив-техник, методик документларны пропагандалау;<br>2.2. Предприятиеләр хезмәткәрләренә профилактик медицина тикшерүләрен узу өчен шартлар тәэмин итү;<br>2.3. Хезмәтне саклау законнарын үтәү буенча район предприятиеләренә һәм оешмаларына комплекслы, максатчан тикшерүне оештыру;<br>2.4. Кече һәм урта бизнес өлкәсендә һәм агросәнәгать комплексы предприятиеләрендә хезмәтне саклау проблемалары буенча чаралар эшләү;<br>2.5. Предприятие җитәкчеләренең һәм белгечләренең, шул исәптән агросәнәгать комплексы белгечләренең квалификациясен күтәрү;<br>2.6. Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча Федераль хезмәт күзәтчелегендәге оешмалар җитәкчеләрен һәм белгечләрен укыту | Кыскартылма:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күрүчеләр саны;<br>- җитештерү имгәнүләре һәм җәрәхәтләнүләре белән бәйле бер зыян күргән кешегә исәпләгәндә эшкә яраксызлык көннәре санынннан чыгып;<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы;<br>- авыр физик хезмәт белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы | Учреждениеләрнең билгеләнгән лимитлары чикләрендә агымдагы финанслау (җирле бюджет), бюджеттан тыш чыганаклар | | |
| | 3. Район оешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын | 3.1. Теләче муниципаль районы икътисадының барлык тармаклары предприятиеләрендә, шул исәптән бюджет оешмаларында хезмәт шартларын махсус бәяләү турындагы законнар нигезендә, хезмәт шартларын этаплап махсус бәяләү үткәрү; | Кыскартылма:<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләрнең чагыштырма | Учреждениеләрнең билгеләнгән лимитлары чикләрендә агымдагы финанслау (җирле бюджет), бюджеттан тыш чыганаклар | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | яхшырту | 3.2. Җитештерү контролен үткәрү, шул исәптән лаборатор-инструменталь тикшеренүләр ярдәмендә аккредитацияләнгән лабораторияләр көче белән;<br>3.3. Әйләнә-тирә мохит объектларында канцерферофакторларның лаборатор-инструменталь тикшеренүләрен мәҗбүри үткәрү белән канцергеноос җитештерүен, участокларны, цехларны паспортизацияләүне үткәрү | авырлыгы;<br>- авыр физик хезмәт белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы | |
| | 4. Лаборатор-профилактик чаралар | 4.1. Прививкалар календарена туры китереп, вакцинопрофилактика үткәрү, шул исәптән эпидемиологик әһәмияткә ия объектларда;<br>4.2. ТР ССМ Республика профпатология үзәге шартларында яисә әлеге үзәк белгечләрен җәлеп итеп, 5 ел дәвамында авыр эшләрдә һәм зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләргә вакытлы профилактик медицина тикшерүләрен оештыру;<br>4.3. Профилактик медицина тикшерүләрен уздыруның тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп торуны оештыру;<br>4.4. Предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда кимерүчеләргә каршы дератизация һәм дезинфекция чараларын үз вакытында үткәрүне контрольдә тоту;<br>4.5. Әлеге авырулар барлыкка килү һәм таралу куркынычы төркеме булып торучы эшчеләр арасында СПИД, вируслы гепатитларга каршы профилактик чараларны гамәлгә ашыру | Кыскартылма:<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы;<br>- авыр физик хезмәт белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең чагыштырма авырлыгы | Учреждениеләрнең билгеләнгән лимитлары чикләрендә агымдагы финанслау (җирле бюджет), бюджеттан тыш чыганаклар |